**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Зәй районының Карман авылы;

Лаеш районының Смолдеярово авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Алексеевск районының Войкино авылындагы Совет урамы;

Әтнә районының Күәм авылындагы Коммуна урамы;

Югары Ослан районының Ключище авылындагы Колхоз урамы;

Лаеш районының Лаеш шәһәрендәге Ленин урамы;

Лаеш районының Комлы Кавал авылындагы Каенлык урамы;

Саба районының Сүлә авылындагы Үзәк урам;

Спас районының «КИМ» совхозы поселогындагы Бакча урамы;

Бөгелмә районының Андреевка авылы янындагы, «Колос» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланыла торган территориянең бер өлеше;

Питрәч районы Татар Казысы авылы янындагы, «Макс-Ойл» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориянең бер өлеше.

2. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Лаеш районының Смолдеярово авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы

булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-541 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Зәй районының Карман авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 11 июнендәге ПУ-546 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 15 август
№ ПУ-722